РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ НОВОАЛИМОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423762, село Новое Алимово, улица Г.Тукая, дом 55.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЯҢА ӘЛЕМ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423762, Яңа Әлем авылы . Г.Тукай урамы, 55 йорт.

РЕШЕНИЕ КАРАР

20.04.2020 № 11

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Яңа Әлем авыл җирлеге Советының27.11. 2017 ел № 37 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 1 статьясының 1 пункты нигезендә, «Татарстан Республикасында хайваннар белән эш итү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Советының 27.11.2017 елның 37 номерлы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлегенең төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында " гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
1.1. Кагыйдәләрнең 182 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::
- «Йорт хайваннарын тотуның төп принциплары, шартлары, этләрне урамда йөртү Кагыйдәләре "Татарстан Республикасында хайваннар белән эш итү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында" 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнә;
1.2. Кагыйдәләрнең 186 пунктында «сукбай хайваннарны тоту һәм аулау» сүзләрен «хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген тормышка ашырганда чаралар оештыру " сүзләренә алмаштырырга»
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында (бүлектә) урнаштырырга
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык
Яңа Әлем авыл җирлеге Советы рәисе Д.М.Әнварова